*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№1 (69)

Октябрь, 2025 нче ел

80 ПОБЕДА!

**Бу санда**

*Укытучыма әйтер сүзем!* 2

*Халыкара өлкәннәр көне - укучылар иҗатында* 3

*Традицион мәктәп бәйрәме – “Көзге бал”* 4

*Ял сәгатьләрендә* 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### ЗАМАНА МӘКТӘБЕ. УЛ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ?




22 октябрь көнне район мәдәният йортында гимназиянең "Замана мәктәбе. Ул нинди булырга тиеш?" дип исемләнгән **Ата-аналар университеты** үтте. Анда тәрбия мәсьәләсенә караган, балалар иминлеген кайгырткан чыгышлар тыңланылды.

Бары тик әти-әни һәм мәктәп җитәкләшеп, иңгә-иң терәп, бер юлдан барганда гына камил шәхес тәрбияләү мөмкин.

### СЫЙНЫФ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ФОРУМЫ



1 октябрьдән 3 октябрьгә кадәр Мәскәүнең «Россия» милли үзәгендә Бөтенроссия сыйныф җитәкчеләре форумы булып узды. Ул бөтен илдән меңләгән сыйныф җитәкчеләрен һәм көллият төркемнәре кураторларын берләштерде.

Форумда Татарстан республикасы делегациясе составында 15 педагог катнашты, алар - Казаннан, Мөслим, Лениногорск, Питрәч, Нурлат, Алабуга һәм Лаеш районнары сыйныф җитәкчеләре.

Гимназиябезнең биология укытучысы, 7 нче а сыйныфы җитәкчесе Бариева Ләйсән Фәхәметдин кызы сайлап алу турыннан уңышлы үтеп, ТР делегациясе составында катнашу хокукына ия булды. Быел форумда катнашыр өчен 50000 нән артык педагог гариза тапшырган һәм 1000 иң яхшы укытучы сайлап алынган.

### БӨТЕНРОССИЯ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ




Мөслим гимназиясенең инглиз теле укытучысы, сыйныф җитәкчесе Мөхәммәтҗанова Гөлшат Ильяс кызы "Ата-аналарны агартуның иң яхшы үзәге (программасы)" номинациясендә җиңеп чыкты һәм 2025 елның 21 октябрендә Мәскәү шәһәрендә узучы тантаналы бүләкләү чарасына чакыру алды.

Әлеге чара “Сәләтле ата-аналар мәктәбе” исемле X Бөтенроссия конференциясенең төп өлеше булып тора. Конкурс Россия Мәгариф министрлыгы, Милли ата-аналар ассоциациясе һәм РФ Иҗтимагый палатасы ярдәме белән үткәрелде. Аның төп максаты — гаиләнең тәрбиядәге ролен ныгыту, гаилә кыйммәтләрен үстерү һәм мәктәп белән гаилә арасындагы хезмәттәшлекне киңәйтү.

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

**Укытучы!** Нинди олы мәгънәгә ия бу сүз! Укытучы ул баланы хәреф танырга, укырга, язарга өйрәтү белән чикләнмичә, аны олы тормышта үз урынын таба алырлык шәхес итеп үстерә. Күренекле язучыбыз Фәнис Яруллин юкка гына: «Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» - дип әйтмәгән.

Чыннан да, кирәк чакта безне яклаучы да, мактаучы да, киңәшче дә – укытучылар!

Кадерле мөгаллимнәребез! Сезне узган һөнәри бәйрәмегез белән чын күңелебездән котлыйбыз! Һәрвакыт укучыларыгызның ихтирамын һәм рәхмәтен тоеп эшләгез!

*Чор сулышын ачык тоемлаучы*
*Зыялы һәм затлы кеше Сез.*
*Сезгә карап сокланабыз һәрчак*
*Күңелләрдә туа горурлык.*
*Рәхмәт Сезгә, әле ярый Сез бар*
*Безгә үрнәк булып торырлык!*

### "АВЫЛ УКЫТУЧЫСЫ - 2025"




Әлеге сүзләрне укуга безнең мөгаллимәбез, башлангыч сыйныф укытучысы Муртазина Ләйсән Габбас кызының күз алдыннан барысы да үтәдер: йокысыз төннәр, күпсанлы эзләнүләр, иге-чиге күренмәгән хезмәт, укучылар белән видеодәрес, эссе язу, бер белмәгән укучылар белән, йөзләгән километр читтә урнашкан авылда тәҗрибәле һәм мәртәбәле жюри алдында ачык дәрес күрсәтү... Әле бу без белгәннәре генә, арасында күпмесе күзгә күренми торган хезмәт!

Һәм менә ул - "Авыл укытучысы - 2025" конкурсының 3 дәрәҗә диплом иясе!

## УКЫТУЧЫМА ӘЙТЕР СҮЗЕМ!

***“Мәһим сөйләшүләр”нең укытучылар көненә багышланган чыгарылышында “Нәрсә ул хөрмәт?” дигән темага сыйныф сәгате үтте. Сыйныф сәгатеннән соң, укучыларның бу темага карата туган фикерләрен газетабызда тәкъдим итәбез.***

***Хөрмәт... Бу теләсә кайсы кеше өчен мөһим, ә укытучы, беренчедән хөрмәтле кеше, өстәвенә, зур хәреф белән. Нәкъ менә ул безгә киләчәккә билет бирә һәм аның ярдәмендә без киләчәктә алыштыргысыз булачак бик мөһим күнекмәләргә ия булабыз. Ул игътибарсыз һәм тыңламаучан балалардан акыллы һәм рәхмәтле балалар ясау өчен күпме сабырлык һәм көч сарыф итә.***



Һәркемнең яраткан укытучысы була. Минем өчен андый укытучы - рус теле укытучым Чулпан Алмазовна. Ул иң авыр фән булган - рус теле фәненнән безгә ныклы белем бирү өчен бар көчен куя. Мин шулай ук Мөслим гимназиясендә эшләүче барлык укытучыларны да хөрмәт итәм. Алар көчле рухлы, ташып торган энергияле, мәктәп тормышының һәр минуты күңелле үтсен өчен барлык көчләрен, сәләтләрен куеп эшлиләр.

***Замалова Зәринә***

***


Зилә Зәфәровна, укучыларда туган телгә карата мәхәббәт уятырга тырыша, һәр көнне мәктәпкә ныклы әзерлек белән килә. Ул дәресләрдә тылсымлы итеп, йомшак тавыш белән сөйли. Аның сөйләү тылсымына бирелеп, без дәреснең үткәнен дә сизми калабыз. Татар халкының



күренекле шәхесләре турында ул сәгатьләр буе сөйләргә дә әзер. Укыган әсәрләрне анализларга тотынсак, ул я безнең яшьтәшкә, я киңәшчегә, я тәнкыйтьчегә әйләнә. Укытучыбыз безне үзе артыннан күңел бакчасына җитәкләп алып керә. Монда һәркем үз фикере белән уртаклаша ала. Үзебез дә хыялыбызда Тукай белән “Пар ат”ка утырып, әле Казанга, әле Җаекка юл тотабыз. Укытучыбызның безгә әйткән һәр сүзен, һәр җөмләсен истә калдырасы килә.

***Дәүләтшина Адилә***

***




Мин укытучыларымны бик ихтирам итәм, аларга үзем дә ихлас күңелдән рәхмәтлемен. Алар безне һәр эшне яратып эшләргә, мөстәкыйльлеккә өйрәтәләр. Безне яраталар, безгә ышаналар. Сыйныфта һәркайсыбызның үз вазифасы бар, һәркем үз өлешен кертә.Эшләмичә генә тормышка өйрәнеп булмый, ди безнең сыйныф җитәкчебез Гөлшат Марсовна. Без шул хакыйкатьне яхшы беләбез. Димәк, һәр укытучының балалар укытуда кеткән өлеше бик зур.

***Насирова Мәрьям***

*Сәхифәне Хәйруллина Диләрә әзерләде.*

# ХАЛЫКАРА ӨЛКӘННӘР КӨНЕ - УКУЧЫЛАР ИҖАТЫНДА

*Мөслим гимназиясенең 6 нчы б сыйныфы укучылары яза*


Көмеш кыңгырау

Әби-бабайлы балачак!

Әбием Рәхимә исем-
ле. Әтиемнең әнисе Ар-
ча районы Мәлисә
авылыннан. Гаиләдә ал-
тынчы бала булып туа.
Язмыш җилләре аны Мөс-
лим районына алып килә.
Ул – дөньяда иң ягымлы,
киң күңелле әби. Безне тәмле
ризыклар белән сыйлый. Ә
кичләрен бергәләп саф һава-
да йөреп кайтабыз, телеви-
зор карыйбыз, башваткычлар
чишәбез, ял итәбез. Мин әби-
емә кояш гомере, саулык-
сәламәтлек телим.

Ралина БАРИЕВА.

* * *

Рәмилә әбиемә 66 яшь.
Ул – Арча ягы кызы, Мөс-
лимгә килеп төпләнеп калган. Озак
еллар Мөслим коры сөт заводында
лаборант булып эшләгән. Хәзер лаеклы
ялда. Без – оныкларын тәмледән-тәмле
ризыклар пешереп сыйлый, иртәләрен
иркәләп йокыдан уята, яхшы укыгыз,
дип мәктәпкә озата.
Мин әбиемне бик-бик яратам, аның
белән горурланам. Сәламәт бул, әби-
ем! Бервакытта да йөзеңнән ел-
маю китмәсен, кайгы күрмә.

Сәмир САБИТОВ.

Минем әбием – Венера. Ул
якты йөзле, киң күңелле, бар-
лык бәйрәмнәрдә дә катнашыр-
га өлгерә. Үзе язган җырлар,
шигырьләр белән чыгыш ясый.
Әбием миңа һәрвакыт үрнәк.
Аның «Җырлы яшьлек» дигән
иҗат төркеме бар. Алар хәйрия
концертлары оештыра. Без дә
гаиләбез белән анда катна-
шабыз.
Венера әбием кон-
цертлар гына куеп кал-
мый, тәмле ризыклар
пешереп, безне сый-
ларга, бакчасында
төрледән-төрле чә-
чәкләр үстерергә дә
житешә.

Исламия НУРГАЛИЕВА.

Мөслим гимназиясенең 6Б сыйныфы укучылары.

## Әбием – лаеклы ялдагы укытучы

Минем яраткан әбием бар. Аның исеме - Нина. Аның яше зур, ул бик күпне күргән. Әби 86 яшен тутырды.

Әбием яшь вакытында мәктәптә укытучы булып эшләгән. Укыткан укучылары хөрмәт итәләр, һәрвакыт килеп хәлен белеп торалар.

Әбиебезнең өендә чисталык, тәртип, тәрәзә төпләрендә гөлләре шау чәчәктә утыра. Ул безне тәмле ризыклар пешереп сыйлый. Каникулларны, аның кочаклап каршы алуын сагынып көтеп алабыз. Аның эшләгән вакытындагы мактау кәгазьләре, грамоталары, медальләре бар. Алар әбиебез өчен һәрберсе кадерле, эшләгән вакытындагы тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Ул аларны кадерләп саклый.

Һәр кеше өчен әбисе якын дип уйлыйм мин. Бездә әбиебез белән горурланабыз. Әбиебезнең тагын да озак еллар исән-сау булып яшәвен, авырмавын телибез.

***Тазова Ивилена***

## Дәү әнием

Бу дөньяда якын, яраткан кешеләрем бик күп. Ләкин әниемнән кала, кадерле кешем - ул минем дәү әнием.

Минемчә, дәү әнисе булган һәрбер бала, бу тормышта бик бәхетле. Аның кайнар ашлары, пешкән тәмле ризыклары, назлы җылы сүзләре йөрәккә үтеп керә.

Минем дәү әни дә шундыйларның берсе, ул мине бик ярата. Минем өчен барсын да эшләргә әзер. Бу тормышта агымга каршы барып, бирешмәскә өйрәтүче, төпле киңәшләре белән, мине киләчәккә өндәүче, елаган чакларымда юатучы, уңышларыма сөенүче ул – дәү әнием.

***Минһаҗева Риана***

## Әбиемә булган рәхмәтем

Минем әбием Рәхимә исемле. Минем өчен кадерле, яраткан әби ул.

Рәхимә әби – әтиемнең әнисе.

Ул чыгышы белән Казан артыннан. Әби Арча районы Мәлисә авылында, гаиләдә алтынчы бала булып дөньяга килә. Язмыш җилләре аны Мөслим районына китереп чыгарган.

Мин аны бик яратам. Ул дөньяда иң ягымлы, киң күңелле әбидер. Безне тәмле ризыклар пешереп сыйлый. Буш вакытларымда мин аңа йорт эшләрендә булышам. Ә кичләрен бергәләп саф һавада йөреп кайтабыз, телевизор карыйбыз, башваткычлар чишәбез, ял итәбез.

Хәзергесе вакытта әби лаеклы ялда. Мин аңа кояш гомере, саулык-сәламәтлек телим.

Әбием - без сине бик яратабыз, хөрмәт итәбез!

***Бариева Ралина***

## Әбиләрнең кадерен белик

Минем әбиемнең исеме Рәмилә. Аңа 66 яшь. Ул Арча ягы кызы, Мөслимгә килеп төпләнеп калган. Әбинең ике баласы бар. Кызы – Лилия, ул минем әни инде, улы – Алмаз абый. Әби, балалары кеше булсыннар, үз юлларын тапсыннар дип бик күп көч куйган,

Ул озак еллар Мөслим коры сөт заводында лобарант булып эшләгән. Хәзер лаеклы ялда. Без – оныкларын тәмледән-тәмле ризыклар пешереп сыйлый, иртәләрен иркәләп йокыдан уята, яхшы укыгыз дип мәктәпкә озата.

Мин аны бик-бик нык яратам, аның белән горурланам. Сәламәт бул, әбием! Бервакытта да йөзеңнән елмаю китмәсен, кайгы күрмә.

***Сабитов Сәмир***

## Әбиемнең гаҗәеп таланты

Мине дә яраткан Венера әбием бар. Ул якты йөзле, киң күңелле, барлык бәйрәмнәрдә дә катнашырга өлгерә. Ул үзе язган җырлар, шигырьләр белән чыгыш ясый.

Җырларга көйләрне дә үзе язучы әбием миңа һәрвакыт үрнәк. Аның "Җырлы яшьлек" исемле иҗат төркеме бар. Алар хәйрия концертлары оештыралар. Без дә гаиләбез белән концертларда катнашабыз.

Венера әби концертлар гына куеп калмый, тәмле ризыклар пешереп безне сыйларга да, бакчасында төрледән-төрле чәчәкләр үстерергә дә житешә.

***Нургалиева Исламия***

## ТРАДИЦИОН МӘКТӘП БӘЙРӘМЕ – “КӨЗГЕ БАЛ”

Көз! Гаҗәп сүз! Аңардан назлы моңсулык һәм сагыш бөркелә. Бу елның иң матур вакыты. Көз - ул искиткеч биюдә яфраклар әйләнә торган вакыт. Бу көзге чорда көзге баллар үткәрү юкка гына кабул ителмәгән. 16-17 октябрь көннәрендә гимназиядә “Көзге бал” бәйрәме үтте, анда барлык сыйныф укучылары да катнашты.

Барлык конкурслар да көзге тема белән бәйле иде. Якты, истә калырлык, бер-берсенә охшамаган номерларны бәйрәмгә әзерләү алдан ук башланды. Укучылар рәсемнәр ясадылар, композицияләр эшләделәр. “Иҗади” конкурста барлык сыйныф вәкилләре үзләренең сәнгать номерларын әзерләүдә креатив якын килү күрсәттеләр. Башлангыч сыйныф укучыларының әтиләре дә катнашу, көзге бал бәйрәмен тагын да ямьләндерде.

Бәйрәм һәркемгә: катнашучыларга да, тамашачыларга да ошады! Бүген көз тулысынча үз хокукларына керде һәм без аның килүен билгеләп үттек. Быел көзгә барыбызны да көзге балга җыйганы өчен рәхмәт белдерәбез.








*Хабиров Данияр, 4 нче а сыйныфы укучысы*

## ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

### *Көз турында татар халык мәкальләренең ахырын тап*

| | |
|---|---|
| Көзге көннән язгы | язгы юлга азык ал. |
| Көзге юлга кием ал, | төн яхшы. |
| Көзге көн – арткы акыл, | көз урырсың. |
| Яз сөрсәң, | көзге хөрмәт. |
| Язгы хезмәт - | язгы көн – ярты акыл. |

### *Кайсы хәреф җитезрәк?*

Таблицаны күрсәтелгән хәрефкә башланган сүзләр белән тутыр.

| Хәреф | Хатын-кыз исеме | Ир-ат исеме |
|---|---|---|
| Б | | |
| Д | | |
| Р | | |
| Т | | |

### *КАДЕРЛЕ ГАЗЕТА УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!*

Мавыктыргыч күңелле җәйге яллардан соң, яңа 2025-2026 нчы уку елында сезнең белән очрашуга чиксез шатбыз! «Тылсым+» редакциясе әгъзалары - сезгә яңа уку елында укуда гел «5» билгеләр алуыгызны, буш вакытыгызны файдалы үткәрүегезне телибез! Яңалыкларыгыз, тәкъдимнәрегез булса түбәндәге электрон адреска *tilsim2014@yandex.ru* мөрәҗәгать итә аласыз.

ТЫЛСЫМ+
Октябрь, 2025 нче ел
№1 (69)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Замалова Зәринә
**Корректорлар:** Хәйруллина Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Фәхрәзиева Алинә
**Дизайнер:** Мостафина Рәйлә
**Компьютерда җыючылар:** Вагыйзов Айзат, Сәләмов Наил

*2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә*

**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim2014@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж**: 100